РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**2022 елның 27 мае** **Чистай шәһәре** **№ 15/6**

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советының «Халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 18 июлендәге 35/5 номерлы карары (Чистай муниципаль районы Советының 2019 елның 6 февралендәге 41/2 номерлы, 2019 елның 23 маендагы 44/5 номерлы, 2021 елның 20 октябрендәге 10/9 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 6 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында «проектка, мәсьәләгә» сүзләреннән соң «иҗтимагый фикер алышуларны яисә гавами тыңлауларны оештыручы адресына электрон документ рәвешендә» сүзләрен өстәргә;
1.2. 12 статьяның өченче абзацында түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә:
«Территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителүгә бәйле рәвештә җирлекнең генераль планына үзгәрешләр әзерләнгән очракта, иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә үткәрелергә мөмкин.».

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов